ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2023 Олы Кайбыч ав. №270

2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасына») үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 02 сентябрендәге 2424-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2021-2025 елларга конкуренция үсешенең милли планын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 09 сентябрендәге 402 номерлы карары белән расланган 2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планына («юл картасына»), түбәндәге эчтәлекле бүлек белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Ритуаль хезмәтләр базары | | | | |
| “Күмү һәм җирләү эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 2 пункты нигезендә җирләү эшен оештыруның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуы билгеләнгән. Шулай итеп, әлеге өлкәдә эшне оештыру, федераль законнар нигезендә җирле үзидарә органнары дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла.<br>Эшчәнлекне җайга салу җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын чыгарганда ритуаль хезмәтләрне, төрле милек рәвешләрендәге һәм намуслы конкуренцияне үстерү максатларында җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.<br>Кайбыч муниципаль районында 58 гамәлдәге зират бар. | | | | |
| Зиратларны һәм аларда күмү урыннарын оештыру һәм инвентарьлаштыру, күрсәтелгән реестрларны Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге | 2022-2025 еллар | Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында зиратларның һәм аларда күмү урыннарының реестрлары төзелгән һәм урнаштырылган, зиратларга гамәлдәге күмү урыннары | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырган килеш зиратларның һәм күмү урыннарының реестрларын булдыру һәм алып бару | | | турында белешмәләр кертелгән, %<br>2023 елда - 10%<br>2024 елда - 50%<br>2025 елда - 100%» | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х. Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров